| СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ |
|---|---|---|

РЕШЕНИЕ КАРАР

16.09.2026 Алабуга шәһәре № 82

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 29 декабрендәге 134 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Алабуга муниципаль районы Советының 2021 елның 29 декабрендәге 134 номерлы карары белән расланган Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 статьяның 4.11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.11. Район Башкарма комитеты җитәкчесе өчен контракт шартлары район Советы тарафыннан халыкның тормыш эшчәнлеген турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга кагылышлы өлешендә һәм Татарстан Республикасы законы белән районның җирле үзидарә органнарына федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга кагылышлы өлешендә раслана».

1.1. 4 статьяның 4.11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.21. Башкарма комитет җитәкчесе белән килешү яклар килешүе буенча яисә суд тәртибендә гариза нигезендә өзелергә мөмкин:

1) Район Советы яисә муниципаль берәмлек башлыгы - Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан халыкның тормыш эшчәнлеген турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итүгә кагылышлы хокук бозуларга, шулай ук коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәүгә бәйле рәвештә;

2) Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) (Татарстан Республикасы Премьер-министры) - Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан җирле үзидарә органнарына федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектлары законнары

белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга кагылышлы өлешендә җибәрелгән хокук бозуларга бәйле рәвештә, шулай ук коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәүгә бәйле рәвештә;

3) Башкарма комитет җитәкчесен - җирле үзидарә органнары һәм (яисә) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан контракт шартлары бозылуга бәйле рәвештә».

1.1. 4 статьяның 4.11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.22. Башкарма комитет җитәкчесе коррупциягә каршы тору турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә тапшырыла торган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү нәтиҗәсендә ачыкланган Россия Федерациясе законнары нигезендә Татарстан Республикасы башлыгының (Рәис) гаризасы нигезендә биләгән вазифасыннан коррупциягә каршы тору турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәүгә бәйле рәвештә азат ителергә мөмкин».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль төзелеш һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис урынбасары А.В. Косов